МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.03.2018 г.Казань № 53/2-пр.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» ведомство максатчан программасын раслау турында» 2017 елның 31 мартындагы 70/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы карарын үтәү йөзеннән һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасында төзелгән «Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына субсидияләр бирү турында» 2018 елның 9 февралендәге 082-09-2018-375 номерлы Килешүе нигезендә **боерам**:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» ведомство максатчан программасын раслау турында» 2017 елның 31 мартындагы 70/2-пр номерлы боерыгына (02.05.2017 № 98/2-пр, 31.10.2017 № 243/2-пр боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкның кереш өлешендә «һәм Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы арасында төзелгән 2017 елның 21 февралендәге 082-08-077 номерлы килешү нигезендә» сүзләрен «һәм Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына субсидияләр бирү турында» 2018 елның 9 февралендәге 082-09-2018-375 номерлы

Килешү нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Боерык белән расланган «2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» ведомство максатчан программасын (алга таба – Программа) яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

1.3. Программага 7 нче кушымта өстәргә (кушымта итеп бирелә);

1.4. Боерык белән расланган «2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә грантлар бирү турында нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә) яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

1.5. Нигезләмәгә 5 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

1.6. Нигезләмәгә 8 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

1.7. Нигезләмәгә 9 нчы кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыклары авыл хуҗалыгы кооперативларына «2017 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» программасына кертелгән үзгәрешләр турында хәбәр итәргә тиеш.

3. Әлеге Боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р. Хәбиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының
31.03.2017 № 70/2-пр боерыгы
(Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының
15.03.2018 № 53/2-пр боерыгы
редакциясендә)
белән расланды

# «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү»

# ВЕДОМСТВО МАКСАТЧАН ПРОГРАММАСЫ

**Эчтәлек**

«2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» ведомство масатчан программасының паспорты

Программага 1 нче кушымта

Программага 2 нче кушымта

Программага 3 нче кушымта

Программага 4 нче кушымта

Программага 5 нче кушымта

Программага 6 нчы кушымта

Программага 7 нче кушымта

**Казан – 2017**

# «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» ведомство масатчан программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Ведомство масатчан программасының исеме | 2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |

| | |
|---|---|
| Программаның максаты | Авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренең, авылда кече хуҗалыкларның һәм кулланучылар җәмгыятьләренең керемнәрен арттыру һәм аларның авыл хуҗалыгы продукциясен һәм азык-төлек сату базарларыннан файдалануларын тәэмин итү буенча, авыл җирендә тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән төп механизм буларак, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү |

| | |
|---|---|
| Төп бурычлар | Куелган максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:<br><br>1. Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләре тарафыннан кооперативлар әгъзалары (ассоциация әгъзалыгыннан тыш) хокукларында эшкәртү яисә сату буенча кимендә 10 авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчесен берләштерә торган авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын яисә кулланучылар җәмгыятьләрен төзүне кызыксындыру, әгәр аларның табышының 70 проценты авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату кебек эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан барлыкка килә торган булса;<br><br>2. Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләре тарафыннан җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, транспортировкалау, саклау һәм эшкәртү өчен кооператив җитештерү куәтләрен булдыруга һәм модернизацияләүгә шартлар тудыру. |

| | |
|---|---|
| Программаның күрсәткечләре | 1. Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары санын үз матди-техник базасын үстерә торган 40 берәмлеккә арттыру.<br><br>2. Өстәмә рәвештә 134 даими эш урыны булдыру аша халыкның эш белән тәэмин ителешен арттыру. |
| Программа чараларының тасвирламалары | Кооперативлар әгъзалары (ассоциация әгъзалыгыннан тыш) хокукларында эшкәртү яисә сату буенча кимендә 10 авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчесен берләштерә торган авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм (яисә) кулланучылар җәмгыятьләренә грантлар бирү өчен федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү, әгәр аларның табышының 70 проценты авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату кебек эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан барлыкка килә торган булса. |
| | Түбәндәгеләр өчен грантлар бирү:<br><br>авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, сатуга әзерләү буенча җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү яисә модернизацияләү;<br><br>авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен билгеләнгән җитештерү объектларына җайланмалар һәм техника сатып алу, |

| | |
|---|---|
| | чыгарыла (җитештерелә, эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә җитештерү контроле һәм ветеринария-санитария экспертизасы лабораторияләрен җиһазлау (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатына лаборатор анализ ясау өчен җайланмалар сатып алу). |

| | |
|---|---|
| | Күрсәтелгән җайланмаларның һәм техниканың исемлеге Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана;<br><br>авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын транспортировкалау һәм аларны ташыганда һәм сатканда аларның сакланышын тәэмин итү өчен махсус транспорт, фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алу. Күрсәтелгән җайланмаларның һәм техниканың исемлеге Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана;<br><br>авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен җайланмалар һәм техник чаралар лизингы шартнамәләре буенча взносларның бер өлешен түләү (лизинг предметларының гомуми хакыннан 8 проценттан да артык булмаган күләмдә). |
| Сату сроклары | 2017 - 2020 еллар |
| Программаны үтәүчеләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |

| | |
|---|---|
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнар күләме 1500 миллион сум тәшкил итә (алга таба – млн. сум) – барысы, шулардан еллар буенча:<br>2017 елда – 250 млн. сум,<br>2018 елда – 460,7 млн. сум,<br>2019 елда – 460,7 млн. сум,<br>2020 елда – 460,7 млн.сум.<br>Федераль бюджет – 555 млн.сум, |

| | |
|---|---|
| | шулардан еллар буенча:<br>2017 елда – 120 млн.сум;<br>2018 елда – 145 млн.сум;<br>2019 елда – 145 млн.сум;<br>2020 елда – 145 млн.сум.<br>Татарстан Республикасы бюджеты – 345 млн.сум, шулардан еллар буенча:<br>2017 елда – 30 млн.сум;<br>2018 елда – 105 млн.сум;<br>2019 елда – 105 млн.сум;<br>2020 елда – 105 млн.сум.<br>Кооперативларның үз акчалары – 600 млн.сум, шулардан еллар буенча:<br>2017 елда – 100 млн.сум;<br>2018 елда – 166,7 млн.сум;<br>2019 елда – 166,7 млн.сум;<br>2020 елда– 166,7 млн.сум. |

| | |
|---|---|
| Ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыруның көтеләчәк нәтиҗәләре һәм аның социаль-икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Татарстан Республикасында авыл кулланучылар кооперациясен үстерү, эшкәртү һәм сату белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләре кооперативлары белән авыл хуҗалыгы продукциясен турыдан-туры продукция җитештерүчеләрнең үзләреннән һәм кече хуҗалыклардан сатып алуга юнәлдерелгән озак сроклы хуҗалык элемтәләре булдыру, сатып алынган продукцияне эшкәртү һәм эшкәртелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сатудан алынган керемнең бер өлешен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына өләшү.<br><br>Программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итә:<br><br>- үз матди-техник базасын үстерү проектларын гамәлгә ашыручы кимендә 40 авыл хуҗалыгы кооперативын төзү;<br>- 134 өстәмә даими эш урыны булдыру аша халыкның эш белән тәэмин ителешен арттыру;<br>Түбәндәгеләрне саклау һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру: |

| | |
|---|---|
| | - Ит терлекчелеге продукциясе (кош итеннән тыш) - 71280 тонна;<br>- сөт– 44000 тонна;<br>- бәрәңге һәм яшелчәләр – 180000 тонна;<br>- кош ите – 9000 тонна;<br>- җиләк, җимеш – 16000 тонна. |
| Идарә итү һәм контроль системасы | Программаны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы җаваплы була. |

## КЕРЕШ

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясенә Республика ярдәменең максаты – Татарстан Республикасы һәм, гомумән, Россия Федерациясе халкын үзебездә җитештерелгән азык-төлек продукциясе белән тәэмин итүгә һәм халыкның эш белән тәэмин итүгә, аның керемнәрен арттыруга һәм, шул ук вакытта, үзебезнең авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләрен төбәк, милли һәм дөньякүләм базарларга конкуренциягә сәләтле төп азык-төлек продукциясе чыгаручылар булып җитешүенә ярдәм итә торган күптөрле инновацияләр исәбенә авыл халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү.

Программада авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләреннән кимендә унысын берләштерә торган, эшкәртү һәм сату белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары яисә кулланучылар җәмгыятьләре катнаша, әгәр аларның табышлары авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары эшчәнлегенең шундый ук төрдәге эшчәнлекне (авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату) гамәлгә ашырудан барлыкка килә торган булса (алга таба – кооперативлар).

## 1. Проблеманы тасвирлау һәм аны программачыл ысуллар белән хәл итүнең зарурлыгын нигезләү

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары белән расланган “2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу турында” дәүләт программасының төп максатлары белән беррәттән түбәндәгеләр мөһим бурычлар булып тора:

- импортны алыштыру шартларында эчке һәм тышкы базарларда республика авыл хуҗалыгы продукциясенең конкуренциягә сәсләтлелеген арттыру;
- авыл территорияләрен тотрыклы үстерү;
- авыл хуҗалыгында җирләрне һәр һәм ресурсларны торгызу, алардан нәтиҗәле файдалануны арттыру.

Шул ук вакытта Дәүләт программасы составына керә торган «Кече хуҗалыкларга ярдәм” ярдәмче программасында мөстәкыйль максат буларак кече авыл хуҗалыклары эшчәнлеген үстерүнең зарурлыгы һәм авыл җирлегендә халыкның тормыш дәрәҗәсен яхшырту күздә тотыла.

Югары конкуренцияле базарда эш итеп, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләре (аерым эре вертикаль берләшкән структуралардан тыш) үз продукциясен сатудан табышның кулланучы түли торган бәядән кечкенә бер өлешен алалар. Продукцияне эшкәртүнең һәм сатуның барлык

этапларында барлыкка килә торган табыш авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчегә керми кала, бу исә Дәүләт программасы максатларына ирешү һәм аның бурычларын хәл итү мөмкинлегенә тискәре йогынты ясый.

Россия законнары нигезендә гражданнарның һәм эшкуаплык эшчәнлеге субъектларының кооперация процессы юридик затлар – кооперативлар төзү аша барлыкка килә. Авыл территорияләрендә төзелә торган төрле төрдәге кооперативлар, югарыда күрсәтелгән бурычлардан тыш, үз әгъзаларының заем ресурсларыннан (авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларыннан) файдалануын тәэмин итү, үз әгъзаларын җитештерү һәм көнкүреш продукциясе белән тәэмин итү (кулланучылар җәмгыятьләре), төп фондлардан уртак файдалану (авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативлары) аша халыкны эш белән тәэмин итү бурычын да үтиләр. Шулай итеп, барлык төр авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерү авыл хуҗалыгы җитештерүенең табышлылыгын тәэмин итүдә, авылда эш белән тәэмин итүне саклап калуда, авыл халкының сатып алучанлыгын арттыруда, ахыр чиктә, авыл территорияләрен тотрыклы үстерүдә зарурый шарт булып тора.

Яшь кооператорлар еш кына җитди проблемалар белән очрашалар, шулардан иң мөһиме - башлангыч капитал җитмәү, җәлеп ителгән финанс ресурсларының артык кыйммәт булуы. Кооператив булдыру һәм аны тоту аның әгъзаларыннан авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләрендә һәм авыл халкында булмаган шактый зур матди ресурслар тотуны, йә заемчараларын җәлеп итүне таләп итә, бу кооперативның булачак әгъзалары өстенә зур бурыч йөкли.

Тагын бер проблемаларның берсе - идарә, икътисадый, салым, бухгалтерлык, финанс һәм хокук мәсьәләләре буенча практик тәҗрибәгә нигезләнгән профессиональ консультация хезмәтләре кытлыгы; кооперативлар менеджерларын һәм башка хезмәтләрен әзерләүнең, аларга өстәмә һөнәри белем бирүнең җитәрлек булмавы.

Күрсәтелгән проблемаларны хәл итмичә, авыл җирлегендә эшләүче кооперативлар хосусый бизнеска каршы тора алмаячаклар, яңа эшчәнлек башлый алмыйлар һәм үз эшчәнлекләрен туктатырга мәҗбүр булалар. Бүгенге көндә федераль дәрәҗәдә каралган авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләренә дәүләт ярдәме чаралары, практикадан күренгәнчә, кооперация үсешенә ярдәм итми, чөнки бу чараларны куллану авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчесенең кооперативларда катнашуына, аларны капиталлаштыруга һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күләменең артуына бәйле түгел. Моннан тыш, гамәлдәге ярдәм чаралары халыкның гадәттәге кооперация институтын кулланучылар җәмгыяте буларак тулы

күләмдә үз эченә алмый.

Инерцияле үсеш сценариясен саклап калганда, кооператив секторы үзенең сыйфатлы үсеше өчен чыганак таба алмаячак, шул исәптән авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү өчен куәтләре җитмәгәнлектән керемнәрен даими рәвештә ахыргача ала алмаган авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләренең – кече хуҗалыкларның таркаулыгы аркасында да.

## 2. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаны гамәлгә ашыруның максаты – барлык төр авыл кооперациясен үстерү, барыннан бигрәк, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләренең, кече хуҗалыкларның, кулланучылар җәмгыятьләренең авыл хуҗалыгы продукциясен сату базарларына үтеп керү мөмкинлекләренең төп механизмы буларак авылда авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясе системасын үстерү, авыл җирлегендә тормыш сыйфатын яхшырту.

Программа кысаларында түбәндәге бурычлар хәл ителәчәк:

- авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләре, шулай ук кече хуҗалыклар тарафыннан эшкәртү һәм сату буенча авыл хуҗалыгы кооперативларын булдыруны һәм авылда кулланучылар кооперациясен үстерүне кызыксындыру;

- кооперативның матди-техник базасын булдыру һәм модернизацияләү өчен шартлар тудыру – җитештерү биналарын, корылмаларны, биналарны, цехларны төзү (сатып алу, ремонтлау, модернизацияләү, юнәлешен үзгәртү, торгызу), чыгарыла (җитештерелә, эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә җитештерү контролен, дәүләт ветеринария-санитария экспертизасын уздыру лабораторияләрен җиһазлау (авыл хуҗалыгы продукциясе сыйфатын лаборатор анализлау өчен җайланмалар сатып алу) һәм терлек итен һәм кош итен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр суюу, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен билгеләнгән җайланмалар һәм махсуслаштырылган транспорт, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, модульләр, авыл хуҗалыгы продукциясе өчен контейнерлар сатып алу (шул исәптән лизинг кулланып).

## 3. Масактчан индикаторлар һәм көтелә торган нәтиҗәләр

Программаны гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәсе – бердәм технологик процессның: авыл хуҗалыгы продукциясе чималын җитештерүдән башлап әзер (эшләнгән һәм (яисә) эшкәртелгән) продукцияне сатуга кадәр үзара бәйле звеноларын авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләрен коопративларга берләштерү юлы белән үстерү.

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаларын үстерүгә грант ярдәме чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәсе авыл җирлегендә эшкәртү һәм сату кооперативларының саны артуда, эш урыннарының саны артуда, авылда кадрларны беркетеп калдыруда һәм авыл халкының санын тотрыклануда чагылачак.

Куелган бурычларны хәл итүнең максатчан индикаторлары түбәндәге 1 нче таблицада китерелә:

1 нче таблица

**Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаларын үстерүгә грант ярдәме чараларының план индикаторлары**

| Индикатор исеме | Үлчәү берәмлеге | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт ярдәме чаралары белән үз матди-техник базасын үстергән авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары саны | Берәмлек | 10 | 10 | 10 | 10 |

Индикаторлар исәпләү өчен кирәкле обсолют күрсәткечләр 2 нче таблицада китерелә:

2 нче таблица

**Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаларын үстерүгә грантлар бирү чарараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан ассигнованиеләр күләме**

| Күрсәткеч | Берәм-лек | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына матди-техник базаларын үстерүгә грантлар бирү чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан ассигнованиеләр күләме | млн. сум | 30,0 | 105,0 | 105,0 | 105,0 |

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсе 3 нче таблицада киетерелгән санлы күрсәткечләр белән билгеләнә, алар объективлык, дөреслек, ачыклык һәм каршы торучанлык критерийларына җавап бирәләр.

3 нче таблица

**Програманы гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр**

| Күрсәткеч исеме | Берәмлек | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт ярдәме чаралары белән үз матди-техник базасын үстергән авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары саны | берәмлек | 10 | 10 | 10 | 10 |
| Эш урыннары булдыру | берәмлек | 44 | 30 | 30 | 30 |
| Сатылган авыл хуҗалыгы продукциясе күләменең үсеше | процент | 10 | 10 | 10 | 10 |

2017 – 2020 елларда 40 кооператив төзү һәм аларның матди-техник базасын үстерү түбәндәгеләрне башкарырга мөмкинлек бирәчәк:

1. Кооперативлар эшендә катнашу исәбенә авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләренең авыл хуҗалыгы продукциясен саклау һәм эшкәртү буенча заманча технологияләрдән файдалана алуын тәэмин итәргә;

2. Авыл хуҗалыгы чималын саклау һәм эшкәртү өчен җитештерү базасы булмаган авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләренең аларның җитештерүгә кагылышлы булмаган югалтуларын киметү исәбенә финанс югалтуларын киметергә;

3. Сыйфатлы авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне

кызыксындырырга;

4. Авыл хуҗалыгы продукциясе базарында кече хуҗалыклар эшчәнлегенең конкуренциягә сәләтлелеген арттырырга;

5. Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләренең һәм авыл халкының керемнәрен арттырырга;

6. Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү һәм үзләштерү, шулай ук авыл җирлегендә урнашып яшәүнең гамәлдәге системасын саклап калуөчен шартлар тудырырга;

7. Авыл халкының кече хуҗалыкларда, шул исәптән шәхси ярдәмче хуҗалыкларда мәшгульлеген арттыру һәм авыл җирлегендә гадәттәге тормыш рәвешен саклап калу кебек социаль нәтиҗәгә ирешергә.

## 4. Программачыл чараларның исемлеге һәм тасвирламалары

4.1. Программаны гамәлгә ашыру механизмнары кооперативларга грантлар бирү буенча чараларны башкарганда муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен финанслауга федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирүдән гыйбарәт.

4.2. Грант рәвешендә дәүләт ярдәмен алу өчен кооперативларның түбәндәге бер яисә берничә төр авыл хуҗалыгы продукциясен җыю, кабул итеп алу, саклау, эшкәртүгә эзерләү, сатуга әзерләү, сортларга аеру, берничә тирәнлектә эшкәртү буенча эшчәнлек өстенлек бирә:

ит терлекчелеге продукциясен, терлек сую цехларын да кертеп, – 12 берәмлек (африка дуңгыз чумасы таралу куркынычы булган төбәкләрдә - дуңгызчылыктан тыш);

сөт – 8 берәмлек,

бәрәңге һәм яшелчәләр – 6 берәмлек;

сую, кош итен эшкәртү буенча гамәлдәге авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын реконструкцияләү – 6 берәмлек;

җиләк-җимеш һәм кыргый үсемлекләр буенча – 8 берәмлек.

4.3. Программада эшкәртү яисә сату белән шөгыльләнүче кимендә 10 авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчесен берләштерә торган, гамәлдәге авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары яисә кулланучылар җәмгыятьләре катнаша, әгәр алар табышының 70 проценты авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату кебек эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан барлыкка килә торган булса.

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын сайлап алуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) боерыгы белән расланган конкурс комиссиясе башкара.

4.4. Конкурс буенча сайлап алуда катнашу өчен кооператив

җитәкчесе конкурс комиссиясенә билгеләнгән вакытларда заявка бирә, аңа Программада катнашу таләпләренә туры килүне раслый торган документлар өстәлеп бирелә һәм ике нөсхәдә шул документларның исемлеге тапшырыла. Бер нөсхәсе документларны кабул итү турындагы тамга белән кооперативта кала.

Конкурс буенча сайлап алуда катнашуга заявка биргәндә кооператив җитәкчесе үзләре турында шәхси белешемәләрне эшкәртүгә һәм тапшыруга кооператив әгъзаларының ризалыгын да тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче конкурсның теләсә кайсы этабында үз заявкасын кире алырга хокуклы. Моның өчен кооператив җитәкчесе конкурс комиссиясенә тиешле гариза тапшыра.

Конкурсны узган һәм җиңүче дип танылган Программада катнашучы әлеге Программага 7 нче кушымтадагы форма буенча мәгълүм үрнәктәге сертификат ала.

4.5. Программада катнашучыларны сайлап алуга конкурс түбәндәге өч этаптан тора:

конкурсны һәм аны узыру срокларын ачыктан-ачык игълан итү;

Программада катнашучыларны сайлап алуга заявкалар кабул итү;

Кооперативның үсеш мөмкинлекләрен өйрәнү һәм тапшырылган белешмәләр буенча фактагы җитештерү биналарын (шул исәптән төзелеп бетмәгәннәрен), авыл хуҗалыгы хайваннарын, техника һәм җайланмаларны чагыштырып карау өчен Министрлык вәкилләренең кооперативка чыгуы (заявкалар кабул итү тәмамланган көн белән очрашып сөйләшүне уздыру көненә кадәр аралыкта);

конкурс комиссиясенең заявкалар буенча фикер алышуы һәм конкурста катнашучыларны очрашып сөйләшүгә кертү;

тиешле материалларны биреп бетермәгән мөрәҗәгать итүчеләргә комиссия секретаре тарафыннан конкурс комиссиясе карарларын (беркетмәдән өземтәләр) тапшыру;

кооператив җитәкчесе белән, проектны финанс ягыннан тәэмин итүне үз өстенә алучы банк учреждениесе вәкиле белән (әгәр кредит акчаларын җәлеп итү күздә тотылса), проектның поручительләре һәм проект гамәлгә ашырыла торган җирлекнең җирле үзидарә органы җитәкчесе белән очрашып сөйлшүләр;

мөрәҗәгать итүчеләргә конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан конкурс комиссиясенең карарларын (беректмәдән өземтәләр) тапшыру.

4.6. Программада катнашучыларны сайлап алуга конкурс җәмәгатьчелек өчен ачык алып барылырга тиеш.

Конкурс комиссиясе составына Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләре булмаган әгъзаларының кимендә 50 проценты кертелергә тиеш. Шулай ук иҗтимагый оешмалар, берлекләр

һәм берләшмәләр вәкилләрен, авыл хуҗалыгы кооперативларының ревизия берлекләре җитәкчеләрен кертергә тәкъдим ителә.

Конкурс комиссиясе утырышларына хокук саклау һәм күзәтчелек органнары вәкилләрен, җирле үзиддарә органнары вәкилләрен чакырырга, шулай ук конкурс комиссиясе утырышларына массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең, юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның керүен тәэмин итәргә тәкъдим ителә.

4.7. Кооперативларның матди-техник базасын үстерүгә грант – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Дәүләт программасын раслау турында" 2013 елның 8 апрелендәге 235 номерлы карары белән расланган «2013 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Дәүләт программасы нигезендә башка дәүләт ярдәме юнәлешләре кысаларында кооперативның кире кайтарылмый торган чыгымнарын финанслашу өчен федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан кооператив счетына тапшырыла торган акчалар ул.

Программада катнашучы грант акчаларын түбәндәгеләр өчен тота ала:

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аннан эшләнмәләрне саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортларга аеру, терлек чалу, беренчел эшкәртү һәм сатуга әзерләү буенча җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү яисә модернизацияләү;

авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җиләкләрне, гөмбәләрне һәм җиләкләрне, шулай ук аларның эшләнмәләрен саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортларга аеру, терлек чалу, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү буенча җитештерү объектлары өчен җайланмалар һәм техника сатып алу һәм аларны монтажлау, чыгарыла (җитештерелә һәм эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә җитештерү контроле лабораторияләрен җиһазлау һәм дәүләт ветеринария-санитария экспертизасын уздыру (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатын лаборатор анализлау өчен җайланмалар сатып алу);

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләрен транспортировкалау, ташыганда һәм сатканда аларның сакланышын тәэмин итү өчен махсуслаштырылган транспорт, фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алу;

авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җиләкләрне, гөмбәләрне һәм җиләкләрне, шулай ук аларның эшләнмәләрен саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортларга аеру, терлек чалу, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга

әзерләү, төяү, бушату һәм транспортировкалау буенча җитештерү объектлары өчен җайланмалар һәм техник чаралар лизингы шартнамәләре буенча взнослар өлешен (лизинг әйберләренең гомуми хакыннан иң күбе 8 процентын) түләү.

4.8. Конкурс комиссиясе кооператив чыгымнарын төгәл планын раслый.

Чыгымнар планының һәр статьясы грант акчаларыннан һәм кооперативның үз акчаларыннан бер үк вакытта түбәндәге чагыштырмада финансланырга тиеш: грант исәбеннән – 60 проценттан артыграк түгел һәм кооперативның үз акчалары исәбеннән – 40 проценттан кимрәк түгел.

Чыгымнар планына үзгәрешләр кертергә кирәк булган очракта, бу үзгәрешләр конкурс комиссиясе белән килештерелә һәм аның тарафыннан раслана. Мондый чакта үзгәрешләр проектның куәтен төшерерлек булырга тиеш түгел.

4.9. Алынган грантны кооператив тарафыннан матди-техник базаны үстерүгә тоту расланган чыгымнар планы нигезендә «2017-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» ведомство максатчан программасы буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерүгә грант бирү турында шартнамә төзелгән көннән 24 ай эчендә башкарыла.

4.10. Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары рәисләре матди-техник базаны үстерүгә грантлар акчаларын максатчан тоту турында Министрлыкка квартал саен Министрлык тарафыннан раслан торган форма буенча хисап тапшыралар.

Тапшырыла торган хисапларның дөреслеген тикшереп торуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре (алга таба – Идарәләр) гамәлгә ашыра.

4.11. Министрлык акчаларны барып җитүен һәм кооперативлар тарафыннан максатчан тотылуын тикшереп торуны тәэмин итә.

Кооперативның матди-техник базасын үстерүгә алынган грантның Программада катнашучы тарафыннан максатчан файдаланылмаган очракта, ул сумма Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә тиешле бюджетка кайтарылырга тиеш.

4.12. Грант ярдәме акчаларының сакланышын һәм алардан максатчан файдалануны тәэмин итү максатларында Министрлык Программаны гамәлгә ашыру механизмнарына кагылышлы норматив хокукый актларда Программада катнашучы тарафыннан үз финанслау чыганаклары исәбеннән йөкләмәләрне тәэмин итүне билгели.

4.13. Программада катнашучылар авыл кооперативларының төбәк һәм бөтенроссия съездларында, кооперативлар эшчәнлеге юнәлешләре буенча

фәнни-гамәли конференцияләрдә, тематик күргәзмәләрдә катнашалар, шулай ук консультацияләр үткәрү һәм кооперативлар кадрларының квалификациясен күтәрү курслары аша кооперативлар әгъзаларының белемнәрен арттыру масатын куялар.

Министрлык Программада катнашучыларга ведомство аграр белем бирү учреждениеләре базасында уку программаларыннан файдалануны тәэмин итә.

## 5. Программаны гамәлгә ашыру сроклары

Программа 2017 – 2020 елларда гамәлгә ашырыла.

## 6. Программаны гамәлгә ашыруның социаль, икътисадый һәм экологик нәтиҗәләрен тасвирлау

6.1. Максатка ирешүдә Программаның өлешен бәяләү.

Программаны гамәлгә ашыру авыл хуҗалыгы өлкәсендә Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының түбәндәге стратегик максатларга ирешүенә ярдәм итә: финанс тотрыклылыгы һәм авыл хуҗалыгын модернизацияләү нигезендә үзебезнең авыл хуҗалыгы продукциясенең конкуренциягә сәләтлелеген арттыруга;

авыл территорияләрен тотрыклы үстерүгә, авыл халкының эш белән тәэмин ителешен һәм тормыш дәрәҗәсен арттыруга.

6.2. Программаның социаль, икътисадый һәм экологик нәтиҗәләре.

Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларның һәм крестьян-фермер хуҗалыкларының, кече һәм урта авыл хуҗалыгы оешмаларының авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәренең артуы планлаштырыла.

6.3. Программаны гамәлгә ашырудан хәтәрлекләрне бәяләү.

Программаны гамәлгә ашыруның планлаштырылган нәтиҗәләреннән фактта ирешелгән нәтиҗәләрнең аермасына тәэсир итәргә мөмкин булган тышкы шартларга һәм хәтәрлекләргә түбәндәгеләр керә:

1. Азык-төлек товарларына бәяләрнең критик хәлдә төшүе, шул исәптән чит ил продукциясе керү аркасында;

2. Төзелеш материалларына, техникага һәм җайланмаларга бәяләрнең инфляция темпларына бәйле көтелә торган бәяләрдән артык үсүе;

3. Форс-мажор хәлләр.

Бу хәтәрлекләр кооператив эшчәнлегенә бәйле түгел. Шуңа бәйле рәвештә бу хәтәрлекләрне алдан фаразлап булмый.

## 7. Бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелеген бәяләү

7.1. Программаның икътисадый нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр буенча бәяләнә:

**4 нче таблица**

***Программа буенча бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелеге***

| Күрсәткечләр | Берәм-лек | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2017-2020 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Россия Федерациясе бюджетыннан субсидияләр күләме | млн. сум. | 120 | 145 | 145 | 145 | 555 |
| Татарстан Республикасы бюджеты | млн. сум. | 30 | 105 | 105 | 105 | 345 |
| Кооперативлар акчалары | млн. сум. | 100 | 166,7 | 166,7 | 166,7 | 600 |
| Барысы: | млн. сум. | 250 | 416,7 | 416,7 | 416,7 | 1500 |
| 2. Грантлар исәбенә үзләренең матди-техник базасын булдырган кооперативлар саны | берәм-лек | 10 | 10 | 10 | 10 | 40 |
| 3. Өстәмә эш урыннары булдыру - барысы | берәм-лек | 44 | 30 | 30 | 30 | 134 |

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләүне максатчан индикаторларны куллану нигезендә уздыру максатка ярашлы, аның күрсәткечләрен килешүләрдә билгеләргә тәкъдим ителә.

## 8. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү методикасы

Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары – Программада җиңүчеләр тарафыннан бирелә торган хисаплар нигезендә башкарыла.

Программа чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге шулай ук хисап бирүнең түбәндәге дәүләт статистик һәм ведомство тармак

формалары анализын исәпкә алып башкарыла:

Форма 1-кооператив – «Эшкәртү һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары эшчәнлеге турында белешмәләр»;

Форма 2-кооператив – «Тәэмин итү-сату буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары эшчәнлеге турында белешмәләр»;

Форма 4-кооператив – «Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары эшчәнлеге турында белешмәләр (эшкәртү, тәэмин итү-сату һәм кредит буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш)»;

Форма П-2 «Инвестиция эшчәнлеге турында белешмәләр»;

Форма 6 – Кулланучылар кооперативы агросәнәгате «Агросәнәгать комплексы оешмалары эшчәнлегенең тармак күрсәткечләре турында хисап»;

Форма 10 – АПК «Максатчан финанслау акчалары турында хисап»;

Форма 1-спрК «Авыл хуҗалыгының кредит кулланучылар кооперативлары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат»;

Форма 1-спр «Авыл хуҗалыгының кулланучылар кооперативлары эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат (кредиттан башка)»;

Форма 1-сәүдә «Кулланучылар җәмгыятьләренең сәүдә эшчәнлеге турында белешмәләр»;

Форма 2 «Авыл хуҗалыгы продуктларын, кыргый үсемлекләр, терлекчелекчималын һәм башка төрле чимал сатып алу турында белешмәләр»;

Форма 1-П «Кулланучылар кооперациясе системасында продукция җитештерү турында белешмәләр».

Сыйфатлы ысул: күрсәткечләрнең һәм максатчан индикаторларның план күләмнәренә ирешү.

## 9. Программаны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен нигезләү

Программаны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен нигезләү кооперативларның матди-техник базасын үстерүнең авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүгә һәм түбәндәге юнәлешләр буенча логистик үзәкләрне үстерүгә юнәлдерелгән пилот проектларын гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итү зарурлыгыннан чыгып башкарылды:

1. Яшелчәләр һәм бәрәңге кабул итү, саклау, юуу, сортларга аерыу, фасовкалау буенча логистик үзәк булдыру һәм аны технологик җиһазлау – 6 данә, кабул итү куәте - елга 30 мең тонна, саклау куәте – 12 мең тонна продукция (алга – Логистик үзәк).

2. Сөт эшкәртү буенча җитештерү куәте елга 5500 тонна булган мини заводны "под ключ" комплектацияләү, инфраструктураны һәм коммуникацияләрне кертмичә (алга таба – 8 данә Мини завод).

3. Терлек симертү буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын булдыру һәм үстерү – ит комбинатлары өчен технологик җайланмалар булдыру – 12 данә, тәүлеккә 25-30 баш терлек суярлык һәм тәүлеккә 22,5 тонна ит эшкәртерлек куәт белән, инфраструктуралар һәм коммуникацияләр моңа керми (алга таба – ит комбинатлары).

4. Кош-корт үстерү, сую һәм эшкәртү буенча гамәлдәге авыл хуҗалыгы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын реконструкцияләү – 6 данә, 3000 тонна кош итенә.

5. Җиләк-җимешләр һәм кыргый җимешләр саклау өчен – 1 данә. Монда түбәндәге шартлар үтәлергә тиеш:

1. Грант күләме проектка барлык чыгымнарның 60 процентыннан артмаска тиеш;

2. Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты чагыштырмасы 58 процент һәм 42 процент булырга тиеш.

| | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 |
|---|---|---|---|---|
| Финанслауның берләштерелгән күләме, млн.сум. | 250 | 416,7 | 416,7 | 416,7 |
| Россия Федерациясе бюджетыннан субсидияләр күләме, млн.сум. | 120 | 145 | 145 | 145 |
| Татарстан Республикасы бюджетыннан, млн.сум | 30 | 105 | 105 | 105 |
| Кооперативлар акчалары, млн.сум. | 100 | 166,7 | 166,7 | 166,7 |
| Грант алучы кооперативлар саны | 10 | 10 | 10 | 10 |
| Бер кооперативка уртача грант күләме, млн. сум | 15 | 25 | 25 | 25 |

Программа чараларын гамәлгә ашыруга кирәк була:

барлык финанслау чыганаклары исәбеннән, кооперативларның узган елгы бәяләрдә 1500 млн. сум күләмендә үз акчаларын да кертеп, барлыгы, шул исәптән:

2017 елда – 250 млн. сум; 2018 елда – 416,7 млн. сум; 2019 елда – 416,7 млн. сум; 2020 елда – 416,7 млн.сум.

Федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан, шулай ук бюджеттан тыш чыганаклардан Программаны финаслауның гомуми күләме тиешле финанс елына һәм план чорына бюджетлар төзегәндә төгәлләштерелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының 2017
елның 31 мартындагы 70/2-пр номерлы
боерыгы белән расланган Программага

7 нче кушымта

МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# СЕРТИФИКАТ

*Настоящим сертификатом удостоверяется, что*

___________________________________________

*(Наименование кооператива)*

___________________________________________

*предъявитель свидетельства о государственной регистрации кооператива*

___________________________________________,

*(серия, номер и дата, ОГРН, ИНН кооператива)*

*является победителем конкурсного отбора для предоставления грантов по ведомственной целевой программе «Развитие сельскохозяйственной потребительской кооперации в Республике Татарстан на 2017 - 2020 годы» в 20__ году, утверждённой приказом Министерства сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан от 31.03.2017 № 70/2-ПР и ему предоставляется грант на развитие материально-технической базы в размере ______________________*

*_______________________________________________ рублей.*

*Дата выдачи "___"_______________ 20__ г.*

**Заместитель Премьер-министра
Республики Татарстан -
министр сельского хозяйства
и продовольствия Республики Татарстан** **М.Г.Ахметов**

**Серия 16 № «__» _______**

**Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы**

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы**

# СЕРТИФИКАТ

*Әлеге сертификат белән*

______________________________________________________________,

*(кооператив атамасы)*

*коопративны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күрсәтүче,*

______________________________________________________________

*(сериясе, номеры һәм датасы, ОГРН, кооперативның ИНН)*

*Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2017 елның 31 мартындагы 70/2-пр номерлы боерыгы белән расланган “2017-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасы буенча грантлар бирү өчен сайлап алу конкурсында җиңүче дип таныла һәм аңа үз матди-техник базасын үстерүгә ________________________________*

*__________________________________ сум күләмендә*

*грант бирелә.*

*Татарстан Республикасы*
*Премьер-министры урынбасары –*
*Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы*
*һәм азык-төлек министры* *М.Г. Әхмәтов*

***Серия 16 №_____ “____” ___________***

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2017 елның 31 мартындагы 70/2-пр номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 15.03.2018 № 53/2-пр боерыгы редакциясендә)

**“2017-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә грантлар бирү турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. “2017-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү” ведомство максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә грантлар бирү турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, Программа) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерүнең һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салуның дәүләт программасы турында” 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары нигезендә эшләнде.

Әлеге Нигезләмә авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә грантлар (алга таба – грантлар) бирү тәртибен һәм шартларын, шулай ук грантлар бирүгә сайлап алу конкурсын уздыру тәртибен билгели.

1.2. Грантлар бирүнең максаты Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү өчен шартлар булдырудан гыйбарәт.

1.3. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр:

грант – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү, авыл хуҗалыгы

продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу турында» 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары белән расланган 2013 - 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы нигезендә эшкәртү һәм (яисә) сату буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетына федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яисә) җирле бюджеттан әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында каралган чараларга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү максатларында тапшырыла торган акчалар ул;

авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы – авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләре тарафыннан кооперативлар әгъзалары (ассоциация әгъзалыгыннан тыш) хокукларында эшкәртү яисә сату буенча кимендә 10 авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчесен берләштерә торган, табышының кимендә 70 проценты күрсәтелгән продукцияне эшкәртү һәм сату кебек эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашырудан барлыкка килә торган эшкәртү һәм (яисә) сату буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы (алга таба - кооператив);

конкурс комиссиясе – кооперативларн ы ң матди-техник базасын үстерүгә грантлар бирү өчен кооперативларның заявкаларын сайлап алу максатларында төзелгән ведомствоара конкурс комиссиясе;

чыгымнар планы – мөрәҗәгать итүче тарафыннан конкурс комиссиясе раславына тапшырылган грантны куллану юнәлешләре буенча чыгымнарның статьялап бүленгән сметасы.

1.4. Татарстан Республикасында салым исәбендә торучы һәм грантлар бирүгә сайлап алу конкурсында җиңүчеләр дип танылган кооперативлар грантлар алучылар (алга таба – Алучылар) булалар.

## 2. Грантлар бирү күләмне һәм шартлары

2.1. Грантлар техник-икътисадый нигезләү буенча максатчан чыгымнарны финанслашу шартларында түләүсез нигездә кооперативларның матди-техник базасын үстерүгә җибәрелә.

2.2. Грантлар кооперативларның матди-техник базасын үстерүгә чыгымнар планында билгеләнгән һәр чыгым статьясыннан 60 проценттан артыграк булмаган күләмдә бирелә, бу сумма бер кооперативка җитмеш миллион сумнан артыграк булмаска тиеш.

2.3. Грантлар Алучыларга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы

законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә конкурс йомгаклары буенча бирелә.

2.4. Грантлар кооперативларның матди-техник базасын үстерүгә башка дәүләт ярдәме юнәлешләре кысаларында кире кайтарылмый торган чыгымнарын финанслашу түбәндәгеләр өчен бирелә:

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аннан эшләнмәләрне саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортларга аеру, терлек чалу, беренчел эшкәртү һәм сатуга әзерләү буенча җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү яисә модернизацияләү;

авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җиләкләрне, гөмбәләрне һәм җиләкләрне, шулай ук аларның эшләнмәләрен саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортларга аеру, терлек чалу, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү буенча җитештерү объектлары өчен җайланмалар һәм техника сатып алу һәм аларны монтажлау, чыгарыла (җитештерелә һәм эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә җитештерү контроле лабораторияләрен җиһазлау һәм дәүләт ветеринария-санитария экспертизасын уздыру (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатын лаборатор анализлау өчен җайланмалар сатып алу);

авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләрен транспортировкалау, ташыганда һәм сатканда аларның сакланышын тәэмин итү өчен махсуслаштырылган транспорт, фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алу;

авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җиләкләрне, гөмбәләрне һәм җиләкләрне, шулай ук аларның эшләнмәләрен саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортларга аеру, терлек чалу, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяү, бушату һәм транспортировкалау буенча җитештерү объектлары өчен җайланмалар һәм техник чаралар лизингы шартнамәләре буенча взнослар өлешен (лизинг әйберләренең гомуми хакыннан иң күбе 8 процентын) түләү.

2.5. Грант түбәндәге шартларны үтәгәндә бирелә:

а) конкурска заявка бирү датасына кооперативның эшчәнлек срогы аны дәүләт теркәвенә алган датадан 12 айдан артып киткән булырга тиеш;

б) кооператив законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән булырга һәм Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәнлеген башкарырга тиеш;

в) кооператив авыл хуҗалыгы кооперативларының ревизия берлеге әгъзасы булырга һәм ел саен Министрлыкка үз эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча бәяләмә тапшырырга тиеш;

г) кооперативның төбәк программасында билгеләнгән эшчәнлек (тармак) буенча матди-техник базасын үстерү, җитештерелгән һәм сатыла торган авыл хуҗалыгы продукциясе күләмен арттыру буенча планы, иң күбе 5 ел эчендә үз-үзен аклый торган чыгымнар статьяларын нигезләү

булырга тиеш;

д) кооператив сатып алына торган мөлкәтнең, башкарыла торган эшнләрең, күрсәтелә торган хезмәтләрнең (алга таба – Сатып алулар) исемнәрен, аларның санын, бәяләрен, финанслау чыганакаларын (Грант ачаларын, үз һәм (яисә) кредит акчаларын) күрсәтеп, чыгымнар планын тапшырырга тиеш;

е) кимендә 10 авыл хуҗалыгы кооперативы әгъзалары хокукларында кооператив составында булу;

ж) әлеге Нигезләмәгә 5 нче кушымта нигезендә мөрәҗәгать итүченең түбәндәге йөкләмәләре булу:

кооператив счетына акчалар кергән көннән 24 ай эчендә грант акчаларын үзләштерү турында;

күрсәтелгән чыгымнар планында Сатып алулар хакыннан кимендә 40 процентын, шул исәптән үз акчаларыннан кимендә 10 процентын түләү турында;

грант акчаларын кулланып алынган мөлкәтне кооперативның бүленми торган фондына кертү турында;

алынган гранти акчаларын кооператив әлеге Нигезләмәдә каралмаган максатларга тоткан яисә аны үзләштерү срокларын бозып тоткан очракта, шулай ук грант бирү турында шартнамәнең биш еллык срогы тәмамланганчы кооператив бетсә яисә грант акчаларын кулланып алынган мөлкән читләштерелсә (бүләк итү, арендага тапшыру, алмаштыру яки пай рәвешендә кертү, башка рәвешле кертем ясау яисә читләштерү) грант акчаларны законнар нигезендә тиешле бюджетка кире кайтару турында;

Министрлыкка үз эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча ел саен ревизия бәяләмәсен тапшыру турында;

грант алган елда һәр 3 млн. сумнан чыгып кимендә бер яңа даими эш урыны булдыру турында;

яңа даими эш урыннарын грантны үзләштергән датадан кимендә 5 ел дәвамында саклап калу;

грант алган кооператив тарафыннан сатылган авыл хуҗалыгы продукциясе күләмен ел саен кимендә 10 процентка арттыру турында;
кооперативның үзе җитештергән продукциясен җыю һәм эшкәртү, транспортлау, саклау күләмнәре өлешен, бу кооперативның үзе җитештергән авыл хуҗалыгы чималыннан шул ук кооператив тарафыннан җитештерелгән беренчел эшкәртелештәге продукцияне дә кертеп, шулай ук әлеге кооператив әгъзалары өчен башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) өлешен гомуми күләмдә 50 процентка кадәр җиткерү турында;

финанс-хуҗалык эшчәнлеген грант алган датадан кимендә 5 ел гамәлгә ашыру турында;

з) кооператив җитәкчесе Россия Федерациясе законнары нигезендә үзе турында шәхси белешмәләрне тапшыруга һәм эшкәртүгә ризалыгын бирә;

и) кооператив үзгәртеп кору, бетерелү, бөлгенлеккә төшү

процессында түгел һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруы чикләнмәгән;

к) кооператив әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында билгеләнгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акчалар алучы түгел;

л) кооперативның Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кайтару, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне кайтару буенча түләнми калган бурычы һәм шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында башка түләнми калган бурычы юк;

м) кооперативның Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк;

н) кооперативның матди-техник базасын үстерүгә грант элек бирелгән грант тулысынча үзләштерелеп беткәннән соң кимендә бер ел узгач бирелергә мөмкин.

## Конкурс буенча сайлап алуны уздыру тәртибе

3.1. Конкурс буенча сайлап алуда катнашу өчен мөрәҗәгать итүче Министрлык тарафыннан билгеләнгән срокка түбәндәге документларны тапшырырга тиеш:

3.1.1. Кооперативның матди-техник базасын үстерүгә грант алу өчен конкурста катнашуга заявка (алга таба – заявка) - әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтадагы форма буенча;

3.1.2. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә кәгазен яисә «Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәнең күчермәсен, ул конкурска заявка бирү көненә кадәр бер айдан да алданрак булмаган вакытта алынган булырга тиеш;

3.1.3. Кооператив уставының күчермәсен;

3.1.4. Әлеге Нигезләмәнең 2.4. пунктының икенче абзацында каралган максатларга грант алу өчен мөрәҗәгать иткәндә түбәндәгеләр тапшырылырга тиеш:

дәүләт экспертизасы узган проект-смета документациясенең күчермәсе, локаль сметалар һәм схема-сызымнар белән (эшләр башкарыласы урыннан фото, объект булганда – аның тышкы һәм эчке якларыннан фотолар), аңа үз-үзен җайга салучы оешманың проектлауга рөхсәт күчермәсе өстәлә (грантны төзелеш яисә реконструкцияләү өчен кулланганда);

төзелешкә (реконструкцияләүгә) һәм (яисә) эксплуатациягә тапшыруга рөхсәт (грантны төзелеш яисә реконструкцияләү өчен кулланганда);

төлеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд оешмаларын җәлеп иткәндә яисә хуҗалык ысулы белән башкарганда алдан төзелгән шартнамәләрнең

күчермәләре;

3.1.5. Әлеге Нигезләмәнең 2.4. пунктының өченче абзацында каралган максатларга грант алу өчен мөрәҗәгать иткәндә түбәндәгеләр тапшырылырга тиеш:

җайланмалар сатып алуга алдан төзелгән шартнамәләрнең күчермәләре;

монтажлау эшләрен башкаруга чит оешмаларны җәлеп иткәндә төзелгән шартнамәләрнең күчермәләре;

3.1.6. Әлеге Нигезләмәнең 2.4. пунктының дүртенче абзацында каралган максатларга грант алу өчен мөрәҗәгать иткәндә түбәндәгеләр тапшырылырга тиеш:

җайланмалар һәм техника сатып алуга алдан төзелгән шартнамәнең күчермәсе;

3.1.7. Әлеге Нигезләмәнең 2.4. пунктының бишенче абзацында каралган максатларга грант алу өчен мөрәҗәгать иткәндә түбәндәгеләр тапшырылырга тиеш:

җайланмалар һәм техника лизингы шартнамәләренең күчермәләре;

3.1.8. Бизнес-план;

3.1.9. Кооперативның бүленми торган фондының счетында чыгымнарның һәр статьясы суммасыннан кимендә 40 процент күләмендә кооперативның үз акчалары һәм (яисә) кредит акчалары булуын һәм 10 процент күләмендә кооперативның үз акчалары булуын раслый торган документлар.

Үз акчалары һәм (яисә) кредит акчалары булуын раслый торган документлар түбәндәгеләр була:

кооперативның кредит оешмасында ачылган счетыннан өземтә;

тиешле акчалар бирелү турында кредит оешмаларында алынган кредит шартнамәләре күчермәләре;

3.1.10. Кооперативта булган күчемсез мөлкәт объектларына хокуклар турында Күчемсез мөлкәтнең дәүләт реестрыннан алынган, вәкаләтле орган тарафыннан танықланган һәм конкурска заявка бирү көненә кадәр 30 көннән дә алданрак булмаган вакытта бирелгән өземтәләр күчермәләре (алар булса);

3.1.11. Кооперативның матди-техник базасын үстерүгә чыгымнар планы проекты, әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтадагы форма буенча;

3.1.12. Мөрәҗәгать итүченең әлеге Нигезләмәнең 2.5 пунктындагы «ж» пунктчасында каралган шартларны үтәү турында йөкләмәсе;

3.1.13. Әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта нигезендә шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;

3.1.14. Мөрәҗәгать итүченең әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтадагы форма буенча анкетасы;

3.1.15. Урнашкан урыны буенча кооперативны салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

3.1.16. Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләү срогы җиткән салымнар, җыемнар

һәм башка түләүләр буенча бурычы булмау турында үз инициативасы белән белешмә;

3.1.17. Авыл хуҗалыгы кооперативларының ревизия берлегеннән кооперативның анда әгъза булуы һәм кооператив әгъзаларының саны турында белешмә;

3.1.18. Узган календарь елы өчен бухгалтерлык (финанс) хисабы күчермәсе, аны кабул итү турында салым органы тамгасы белән, йә, хисап электрон рәвештә бирелгән очракта, гомуми (махсус) салым салу режимын кулланучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары өчен - кабул итү турындагы квитанция белән;

3.1.19. Авыл хуҗалыгы кулланучылар коооператвы яисә кулланучылар җәмгыяте вәкиленең шәхесен таныклый торган документы күчермәсе;

3.1.20. Авыл хуҗалыгы кулланучылар коооперативы яисә кулланучылар җәмгыяте вәкиленең шәхес вәкаләтләрен таныклый торган документы күчермәсе.

3.2. Тапшырылган документларның дөреслеге һәм төгәллеге өчен җаваплылык кооператив җитәкчесенә йөкләнә. Документларны әзерләүгә һәм конкурс комиссиясенә тапшыруга бәйле барлык чыгымнарны кооператив җитәкчесе тота.

Таныкланырга тиешле һәм берничә биттән торучы документлар тапшырганда, аларның һәр бите таныклана. Документларның оригиналлары проектны яклаганда конкурс комиссиясе тарафыннан күчермәләрне чагыштыру өчен тапшырыла.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар сайлап алу конкурсы уздыру турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән срокларда һәм адрес буенча тапшырыла.

Грант бирү тәртибе һәм документлар формалары турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында: http: //agro.tatarstan.ru/ – «Фермерларга, авыл хуҗалыгы кооперативларына грантлар һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр» бүлегендә, алга таба – «Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү» бүлекчәсе (алга таба - Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүче үз теләге белән конкурс комиссиясенә (очрашып сөйләшкәндә) кооперативны программада потенциаль катнашучы буларак уңай тасвирлый торган һәм конкурс комиссиясе карарына тәэсир итә торган түбәндәге документларны тапшырырга мөмкин:

а) муниципаль хакимият органнарыннан кооперативның үсешен, аның җитештерү күрсәткечләре динамикасын, шулай ук грант бирүнең максатчан булуын һәм аның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген тасвирлый торган күрсәтмә хатларын;

б) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының җир кишәрлегенә һәм (яисә) күчемсез мөлкәт объектына милекчелк хокукы турында өземтә күчермәсен (йә милекчелек

хокукын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен) яки күчемсез мөлкәтне заявка биргән көннән кимендә биш елга арендалау шартнамәсе күчермәсен;

в) җитештерү биналарының (шул исәптән төзелеп бетмәгән төзелешнең), авыл хуҗалыгы хайваннарының, техника һәм җайланмаларның фотографияләрен;

г) заявка бирелгәннән соң әлеге Нигезләмәнең 3.1. пунктында билгеләнгән таләпләр нигезендә эшләнеп беткән документларны;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан язмаларны.

## 4. Заявкаларны кабул итү һәм теркәү

4.1. Грантлар бирү буенча сайлап алу конкурсында катнашуга заявкаларны кабул итү башлану турында белдерү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында: http: //agro.tatarstan.ru/ – «Фермерларга, авыл хуҗалыгы кооперативларына грантлар һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга субсидияләр» бүлегендә урнаштырыла.

Белдерүдә конкурс уздыруның урыны һәм вакыты (кимендә 30 календарь көн кала), элемтә телефоннары, Министрлык сайтының конкурс шартлары турында, заявкалар бирү һәм норматив хокукый документлар белән танышу тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла торган бүлеге күрсәтелә.

4.2. Заявкалар кабул итә башлау срогы белдерү басылып чыккан көннән соң килүче көн була. Белдерүдә күрсәтелгән срок узгач кооперативлардан заявкалар кабул ителми.

Алынган заявкалар һәм документлар алар кергән саен заявкаларны теркәү кенәгәсендә теркәлә, ул номерланган, төпләнгән һәм конкурс комиссиясе секретареның имзасы таныкланган һәм Министрлык мөһере белән беркетелгән булырга тиеш. Теркәгәндә заявкага керү номеры бирелә.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар конкурс комиссиясе секретарена кәгазьдә килеш тапшырыла. Кооператив җитәкчесе тарафыннан конкурс комиссиясе тапшырыла торган барлык документларның исемнәре, номерлары һәм даталары, алардагы битләр саны ике нөсхәдә төзелә торган исемлеккә кертелә. Тапшырылган документлар конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан исемлек белән чагыштырып тикшерелгәннән соң (әлеге Нигезләмәгә 6 нчы кушымта), алар, конвертка салынып, ябыштырыла, конверт кооператив җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булса) белән таныклана. Конвертта шулай ук программаның исеме, кооперативның исеме һәм адресы, кооператив җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, проектның юнәлеше күрсәтелә. Исемлек конвертка салынмый. Документларны кабул иткәндә исемлектә документлар кабул итүне раслый торган тамга куела, кабул итү датасы һәм

теркәү номеры куела. Исемлекнең кабул итү тамгасы белән белән бер нөсхәсе кооператив җитәкчесендә кала, ә икенчесе документлар пакетына өстәлеп куела.

Заявкаларны һәм документларны кабул иткәндә аларның тулылыгы һәм билгеләнгән таләпләргә туры килүе тикшерелми.

4.3. Министрлык конкурс документлары кабул итү тәмамланган көннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча документларны конкурс комиссиясенә җибәрә.

## 5. Конкурс комиссиясенең функцияләре һәм бурычлары

5.1. Конкурс комиссиясе үз эшчәнлегендә законнарга, әлеге Нигезләмәгә таяна авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләренә дәүләт ярдәме инфраструктурасын тәшкил итүче оешмалар белән хезмәттәшлектә үз эшен оештыра.

5.2. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары түбәндәгеләр була:

кооперативларның матди-техник базасын үстерүгә грант алу өчен мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырылган конкурс документациясен вакытында, ачык һәм объектив карауны тәэмин итү;

проектларның тулылыгын һәм дөреслеген, икътисадый нәтиҗәлелеген, Татарстан Республикасы икътисады өчен социаль әһәмиятлелеген һәм аңа дәүләт ярдәме күрсәтүнең максатка ярашлы булуын билгеләү өчен аларга экскретиза уздыру;

конкурста җиңүчеләрне һәм аларга бирелә торган грантлар күләмнәрен билгеләү.

5.3. Конкурс комиссиясе Министрлык боерыгы белән кимендә 12 кешедән оештырыла һәм аның составына конкурс комиссиясенең рәисе, рәис урынбасары, конкурс комиссиясе әгъзалары һәм секретаре (тавыш бирү хокукына ия түгел) керә. Конкурс комиссиясе составына дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләре, иҗтимагый оешмалар, авыл хуҗалыгы өлкәсендә берлекләр, берләшмәләр һәм белем бирү оешмалары вәкилләре керә. Конкурс комиссиясе составында дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләре саны – 50 процентган кимрәк.

Конкурс нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынучы затлар (шул исәптән конкурста катнашуга гариза биргән йә бу заявкаларны биргән кооперативларда торучы затлар) яки конкурста катнашучылар тәэсир итәргә мөмкин булган затлар комиссия әгъзалары була алмыйлар.

Конкурс комиссияс рәисе:

конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм аңа йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була;

конкурс комиссиясе әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;

конкурс комиссиясе утырышларын алып бара, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен әзерләүне һәм конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларның үтәүен тикшереп тора.

5.4. Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, утырышта конкурс комиссиясе рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын үти.

5.5. Конкурс комиссиясе секретаре:

заявкалар кабул итү тәмамланганнан биш эш көне эчендә конкурс комиссиясе утырышында каралырга тиешле документлар белән заявкалар исемлеген булдыра;

конкурс комиссиясе утырышлары көн тәртибе буенча материаллар әзерләүне оештыра, документлар әйләнешен һәм утырышларда конкурс комиссиясе әгъзаларының катнашуын, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерүне тәэмин итә;

5.6. Конкурс комиссиясе әгъзалары:

конвертларны ачалар һәм әлеге Нигезләмәдә каралган документларның булуын тикшерәләр;

кооперативның һәм тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерәләр;

баллар санын исәплиләр, аларны бәяләү ведомостена кертәләр;

мөрәҗәгать итүчеләрнең чыгымнар планнарын, аларның дәлилләнгән булуын исәпкә алып, килештерәләр;

бирелә торган грант күләмен килештерелгән чыгымнар күләмендә билгелиләр, әмма бу әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында билгеләнгән максималь күләмнән артмаска тиеш;

Грантлар алучыларның гаризалары нигезендә бизнес-планнарны аларның гамәлдә булу чорында үтәү графигын кабат карыйлар.

5.7. Конкурс комиссиясе, заявкалар кабул итү тәмамланган вакыттан 14 эш көненнән дә соңга калмыйча, конкурс комиссиясе утырышын уздыра, мөрәҗәгать итүчеләрнең тапшырылган документларын карый, кооперативларга грантлар бирү йә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, ул конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе (алга таба – беркетмә) итеп рәсмиләштерелә;

заявкалар кабул итү тәмамланганнан соң 10 көн эчендә конкурс комиссиясе утырышын оештыра, мөрәҗәгать итүчеләрне очрашып сөйләшү өчен утырышка чакыра.

Очрашып сөйләшү барышында конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы заявкалардагы мәгълүмат һәм бирелгән сорауларга мөрәҗәгать итүченең җаваплары нигезендә тиешле карарны кабул итә һәм һәр кооперативка карата тавыш бирү кәгазенә язып куя, шунда ук бирелә торган грант күләмен күрсәтә.

5.8. Конкурс комиссиясенең карары, аның составының яртысы булганда, гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Конкурс комиссиясе секретареның сайлау хокукы юк.

Билгеләнгән критерийлар нигезендә бертигез баллар алган берничә дәгъвачы булганда, мөрәҗәгать итүчеләрнең санлы составы буенча грантлар саны фактта җитәрлек булмаса, грант «Конкурска заявкалар теркәүнең 1 нче

номерлы журналы»нда заявкасы алданрак вакытта теркәлгән мөрәҗәгать итүчегә бирелә.

Тавыш бирү кәгазьләрендә конкурс комиссиясе әгъзалары белдергән карарлар нигезендә секретарь конкурс бюллетенен төзи. Тавыш бирү кәгазьләре һәм конкурс бюллетене беркетмәгә кушыла.

5.9. Конкурс комиссиясе утырышлары кирәк саен уздырыла. Конкурс комиссиясе әгъзалары утырышка рәис хәл итүе буенча чакырыла.

Конкурс комиссиясе утырышларында аның әгъзаларының яртыдан артыгы катнашса, ул тулы хокуклы була.

5.10. Конкурс комиссиясе мөрәҗәгать итүчеләр тапшырган документларны анализлау нигезендә, түбәндәге критерийларга таянып, конкурста җиңүчеләрне билгели:

| № | Критерий исеме | Күрсәткеч-ләр | Балларда бәяләү |
|---|---|---|---|
| 1 | Конкурста сайлап алуда катнашу өчен заявка биргән вакытка мөрәҗәгать итүченең милкендә һәм (яисә) кимендә 5 елга озак сроклы арендада авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү өчен билгеләнгән җитештерү бинналары булу | юк | 0 |
| | | 300 квадрат метрга кадәр | 5 |
| | | 300 квадрат метрдан югары | 10 |
| 2 | Һәр 3 млн. сум күләменә эш урыннары булдыру | 2 | 5 |
| | | 3 һәм аннан күбрәк | 10 |
| 3 | Бизнес-план нигезендә үзен аклау срогы | 5 елдан күбрәк | 0 |
| | | 3 елдан 5 елга кадәр | 5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 3 елга кадәр | 10 |
| 4 | Матди-техник базаны үстерүгә чыгымнар планыннан үз акчалары суммасы | 41-45 процент | 5 |
| | | 45 проценттан күбрәк | 10 |
| 5 | Кооператив әгъзалары саны | 11-15 әгъза | 5 |
| | | 15 әгъзадан күбрәк | 10 |
| 6 | Кооператив җитәкчесенең эшлекле сыйфатларын бәяләү, профессионализм, социаль һәм бюджет җаваплылыгы | иң югары балл – 10 | |

5.11. Баллар бары тик тегелгән документлар буенча гына исәпләнә, конкурс комиссиясе утырышына тапшырылган документлар балл суммасына кертелми. Иң күп җыелган баллар 60ка тиң. Конкурс комиссиясе тарафыннан уңай карар чыгару өчен 20 балл җыярга кирәк. Иң күп баллар җыйган мөрәҗәгать итүчеләр сайлап алу конкурсында җиңүчеләр булалар.

5.12. Беркетмә конкурс комиссиясе рәисе яисә аның урынбасары, секретаре һәм конкурс комиссиясенең утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмә имзаланганнан соң Министрлык 5 эш көне эчендә конкурс нәтиҗәләрен раслау турында боерык чыгара һәм Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарәләр) конкурс комиссиясе кабул иткән карар турында конкурста катнашучыларга мәгълүмат җиткерү өчен язмача хәбәрнамә җибәрә.

Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат, җиңүчеләр турында Министрлык боерыгы расланган көннән 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

5.13. Конкурс комиссиясе, чыгымнар планы нигезендә объектив сәбәпләр буенча грант акчаларын тотуга тоткарлык тудыра торган эшкуарлык эшчәнлеге шартлары үзгәргән очракта, йә мөрәҗәгать итүче проектны гамәлгә ашырудан баш тарткан очракта, күрсәтелгән үзгәрешләрне килештерү һәм өстәмә утырыш уздыру турында карар кабул итә.

Конкурс тәмамланганнан соң 30 эш көне эчендә барлык заявкаларны һәм документларны, шулай ук конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителгән барлык документларны Министрлык архивына саклауга

тапшыра, алар анда грант үзләштерелгәннән соң биш ел саклана.

5.14. Конкурска бирелгән заявкалар саны яисә грантлар откан кооперативлар саны финанслау бүленгән кооперативлар санынннан кимрәк булган очракта, Министрлык өстәмә конкурс игълан итә, ул әлеге Нигезләмә тәртибендә уздырыла.

## 6. Грантны бирү һәм кайтару тәртибе

6.1. Министрлык Татарстан Республикасы бюджет акчаларын төп бүлүче була, акчаларны Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсендә ачылган үзенең шәхси счетыннан биш эш көне эчендә Идарәләрнең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсе территориаль бүлекчәләрендә ачылган шәхси счетларына күчерә.

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча алучылар кысаларында Татарстан Республикасы муниципаль районына тиешле грантлар турында җыелма белешмә-исәп-хисаплар һәм шартнамәләр Идарәгә акчалар күчерү өчен нигез була.

6.2. Министрлык грант алуга тапшырылган документларны кергән саен кенәгәдә теркәп бара, ул номерланырга, тегелергә, Министрлык мөһере белән беркетелергә тиеш. Теркәү язуында теркәлү номеры, документларны кабул итү датасы һәм конкурс комиссиясе нәтиҗәләре буенча грант суммасы булырга тиеш.

6.3. Документлар теркәлгән көннән соң биш эш көне эчендә Министрлык _ кергән документларны тикшерә һәм грант алучы тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 6.1. пункты нигезендә тапшырылган чыгымнар планын, белешмә-исәп-хисапны һәм шартнамәне имзалый.

6.4. Мөрәҗәгать итүчегә грант бирүдән баш тарталар, әгәр:

әлеге Нигезләмәнең 3.1., 3.2., 6.1. пунктларында каралган документлар пакеты тулы тапшырылмаган булса;

әлеге Нигезләмәнең 3.1., 3.2., 6.1. пунктлары нигезендә тапшырылган документларда белешмәләрнең, исәп-хисапларның факттагы белешмәләргә, исәп-хисапларга туры килмәве ачыкланса.

6.5. Министрлык грантны Идарәләрнең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсе территориаль бүлекчәләрендә ачылган шәхси счетларына күчерү өчен Татарстан Республикасы Финас министрлыгының Казначылык департаментына түбәндәгеләрне тапшыра:

Министрлыкның конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен раслау турында боерыгын;

әлеге Нигезләмәнең 6.1. пункты нигезендә күрсәтелгән, әлеге Нигезләмәнең 6.3. пункты нигезендә имзаланган җыелма белешмә-исәп-хисапны һәм шартнамә күчермәсен.

6.6. Идарә үзенең шәхси счетына грантлар кергән көннән биш эш көне эчендә аларны кооперативларның Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы идарәсе территориаль бүлекчәләрендә ачылган шәхси счетларына күчерә.

6.7. Грант бирүдән баш тартуга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә агымдагы ел дәвамында шикаять белдерелә.

6.8. Чыгымнар планы нигезендә грант акчаларын һәм үз акчаларын тотып бетергәннән соң, кооператив җитәкчесе әлеге Нигезләмәгә 10 нчы кушымта нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы тарфыннан расланган «Җыелма реестр»ны, акчаларның кооператив тарафыннан вакытында һәм максатчан кулланылуын раслый торган хисап-финанс документларын (грант акчаларының тотылышын раслый торган исәп-хисап счетыннан банк өземтәсе, сату-алу шартнамәләре, түләү йөкләмәләре, накладнойлар, счет-фактуралар, фото) тапшырырга тиеш. Грантларның максатчан кулланылуын Министрлык тикшереп тора.

6.9. Кооперативлар грантны алган көннән 24 ай эчендә Министрлыкка грантларны максатчан куллану турында йомгаклау хисабын тапшыралар, ул Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча Идарә башлыгы белән килештерелгән булырга тиеш.

6.10. Грантны үзләштереп бетергәннән соң 5 ел дәвамында кооператив Министрлык өчен ирешелгән күрсәткеч нәтиҗәләре турында яртыеллык һәм еллык хисаплар әзерли. Хисаплар Идарәләргә хисап чоры узганнан соң 10 эш көне эчендә Министрлык боерыгы белән расланган формалар буенча тапшырыла. Идарәләр хисапларкергәннәнсоң 10 эш көне эчендә аларны Министрлыкка җибәрә.

Хисаплар имза һәм кооператив мөһере (булса) белән таныкланырга тиеш.

6.11. Кооператив тарафыннан хисап вакытында тапшырылмаса, Идарә законнар нигезендә дәүләт ярдәме күрсәтүне туктатып тора.

6.12. Алучы яртыеллык хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча Грантны куллануның нәтиҗәлелеге турында әлеге Нигезләмәнең 11 нче кушымтасы формасы буенча хисап тапшырырга тиеш.

6.13. Грант Татарстан Республикасы федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау лимитларын исәпкә алып бирелә. Агымдагы елда бюджет акчалары сайлап алу кокурсын узган заявкаларны канәгатьләндерү өчен җитәрлек булмаган очракта, аларны финанслау иң күп җыелган баллар саны буенча әлеге Нигезләмә нигезендә чиратлылык тәртибендә башкарыла.

6.14. Бирелгән грантларны Татарстан Республикасы бюджетына бюджет законнары нигезендә кире кайтару Министрлыктан тиешле таләп алганнан соң 60 эш көне эчендә түбәндәге очракларда башкарыла: әгәр әлеге Нигезләмәдә һәм шартнамәдә билгеләнгән аларны бирү тәртибе һәм

шартлары бозылу фактлары ачыкланса, конкурска дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирелгән булса, хисап тапшырылмаса, грант акчалары максатчан кулланылмаса, шулай ук грантлар белән нәтиҗәле күрсәткечләргә ирешелмәгән һәм максатчан күрсәткечләрне бозган очракта.

6.15. Шартнамәдә каралган очракларда, грантның 24 ай эчендә кулланылмый калган өлеше әлеге срок узгач 30 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

6.16. Әлеге Нигезләмәнең 6.13 һәм 6.14 пунктларында күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджетына ихтыярый рәвештә кайтарудан баш тарткан очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри тәртиптә алынырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек
министрлыгының
31.03.2017 № 70/2-пр
боерыгы (Татарстан
Республикасы Авыл
хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгының
15.03.2018 № 53/2-пр
боерыгы редакциясендә)
белән расланган
Нигезләмәгә
5 нче кушымта

**«2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерү» ведомство максатчан программасында катнашучының йөкләмәсе**

Татарстан Республикасы ______________________ муниципаль районының

_______________________________________________________________

(кооперативның исеме)

кооператив счетына акчалар кергән көннән 24 ай эчендә грант акчаларын үзләштерү турында;

чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алулар бәясеннән кимендә 40 процентын, шул исәптән кимендә 10 процентын үз акчалары исәбеннән түләү турында;

грант акчаларын кулланып алган мөлкәтне кооперативның бүленми торган фондына кертү турында;

грант акчалары әлеге Нигезләмәдә каралган максатларга тотылмаган яисә аны үзләштерү срокларын бозып тотылган очракта, шулай ук кооператив бетерелгәндә яки Грант акчаларына алынган мөлкәте Грант бирү шартнамәсенең биш еллык гамәли срогы узганчы читләштерелгән (бүләк ителгән, арендага тапшырылган, алыштырылган яки пай рәвешендә взноска кертелгән, кертем итеп урнаштырылган яисә башкача читләштерелгән) очракта, законнар нигезендә грант акчаларын тиешле бюджетка кайтару турында;

ел саен үз эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча ревизия бәяләмәсен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына тапшыру турында;

грантны алган елда грантның һәр 3 млн. сумы күләменә кимендә бер яңа даими эш урыны, әмма бер яңа даими эш урыныннан да ким түгел, булдыру турында;

яңа даими эш урыннарын грант үзләштерелгәннән соң кимендә 5 ел буена саклап калу турында;

грант алган кооператив тарафыннан сатылган авыл хуҗалыгы продукциясе күләмен ел саен кимендә 10 процентка арттыру турында;

кооперативның үзе җитештергән авыл хуҗалыгы продукциясен җыю һәм эшкәртү өлешен, транспортировкалауны, саклауны тәэмин итү, әлеге кооператив әгъзалары җитештергән авыл хуҗалыгы чималыннан кооператив үзе җитештергән продукцияне башлангыч эшкәртүне дә кертеп, шулай ук башкарылган эшләрдән (күрсәтелгән хезмәтләрдән) шул кооператив әгъзалары өчен гомуми күләмдә кимендә 50 процентын тәэмин итү турында;

грант үзләштерелгән датадан кимендә 5 ел финанс-хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында.

Кооператив җитәкчесе ________________________________________

__________
(имза) (Фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Мөһер урыны(булса) 20___елның _____ ________

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
31.03.2017 № 70/2-пр
боерыгы (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
15.03.2018 № 53/2-пр
боерыгы редакциясендә)
белән расланган
Нигезләмәгә

8 нче кушымта

«Раслыйм»:

Конкурс комиссиясе рәисе

Р.Р. Хәбипов ________
(имза)

20___елның «_____» ________

**Татарстан Республикасы __________ муниципаль районының**

________________________________________________

(кооператив исеме)

**матди-техник базасын үстерүгә**

**ЧЫГЫМНАР ПЛАНЫ**

| □/□ № | Чыгымнар статьясы исеме | Финанслау чыганаклары, мең сум |
|---|---|---|

| | | Барлыгы | шул исәптән | |
|---|---|---|---|---|
| | | | грант, 60 процент | үз акчалары |
| 1 | Авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, сатуга әзерләү буенча җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү яисә модернизацияләү. | | | |
| 2 | Авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен билгеләнгән җитештерү объектлары өчен җайланмалар һәм техника сатып алу һәм монтажлау, чыгарыла (җитештерелә, эшкәртелә) торган продукциянең сыйфатына һәм иминлегенә җитештерү контроле һәм ветеринария-санитария экспертизасы лабораторияләрен җиһазлау (авыл хуҗалыгы продукциясенең сыйфатына лаборатор анализ ясау өчен җайланмалар сатып алу). | | | |
| 3 | Авыл хуҗалыгы продукциясен һәм аның эшләнмәләре продуктларын транспортировкалау һәм аларны ташыганда һәм сатканда аларның сакланышын тәэмин итү өчен махсус транспорт, фургоннар, тагылмалар, ярымтагылмалар, вагоннар, контейнерлар сатып алу. | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү, төяп җибәрү, бушату өчен җайланмалар һәм техник чаралар лизингы шартнамәләре буенча взносларның бер өлешен түләү (лизинг предметларының гомуми хакыннан 8 проценттан да артык булмаган күләмдә). | | | |
| | **Барысы:** | | | |

Кооператив җитәкчесе ________________________________

__________
(имза) (Фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Мөһер урыны(булса) 20___елның _____ ________

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек
министрлыгының
31.03.2017 № 70/2-пр
боерыгы (Татарстан
Республикасы Авыл
хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгының
15.03.2018 № 53/2-пр
боерыгы редакциясендә)
белән расланган
Нигезләмәгә
9 нчы кушымта

**«2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» ведомство максатчан программасы буенча авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерүгә грант бирү турында**
**ШАРТНАМӘ**

Казан шәһәре № __________ 20____елның __ ______

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, алга таба «Грант бирүче» дип аталачак, бер яктан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 316 номерлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов йөзендә, һәм, икенче яктан, Татарстан Республикасы _______________ муниципаль районының авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы, ОГРН___________, ИНН____________, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының Устав нигезендә эш итүче җитәкчесе __________________________ йөзендә, алга таба «Грант алучы» дип атлачак, алга таба бергә «Яклар» дип аталачак, конкурс уздыру йомгаклары буенча (конкурс комиссиясе утырышының 20__елның ___ ______ ____ номерлы беркетмәсе, Грант бирүченең бюджет акчалары бирү турында 20__елның ___ ______ ____ номерлы боерыгы) түбәндәгеләр турында әлеге шартнамәне төзеделәр:

## 1. Шартнамә предметы

1.1. Грант бирүче Грант алучыга авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерүгә грант бирә.

1.2. Грант алучы грантны конкурс комиссиясе тарафыннан расланган чыгымнар планы нигезендә ______________________________________, авыл хуҗалыгы продукциясен, кыргый җимешләрне, гөмбә һәм җиләкләрне, шулай ук бу продуктлар эшләнмәләрен әзерләү, саклау, эшкәртүгә әзерләү, эшкәртү, сортировкалау, терлекләр сую, беренчел эшкәртү, суыту, сатуга әзерләү буенча кулланырга һәм еллык продукция күләмен кимендә _____________________ җиткерергә йөкләмә ала.

1.3. Грант суммасы Грант бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең (алга таба – Идарә) Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетына күчерелә, ә Идарә аны Грант алучының Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетына күчерә һәм ул __________ (____________________________) сум тәшкил итә.
(сүзләр белән языла)

1.4. Шартнамәгә Казначылык күзәтүе «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2017 елның 5 декабрендәге 362-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда Казначылык күзәтүе кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 30 декабрендәге 1722 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 2.2. Грант бирүченең хокуклары һәм бурычлары

2.1. Грант бирүче:

Грант алучының әлеге Шартнамә белән үзенә йөкләнгән бурычларны үтәвен тикшереп тора;

Грант алучыдан проектны гамәлгә ашыруга кагылышлы финанс һәм башка беренчел исәпкә алу документларын соратып ала;

грантның проектны гамәлгә ашыруга гына тотылышын раслау өчен Грант алучы тарафыннан тапшырылган документларны тикшерә, шулай ук проектның фактта гамәлгә ашырылуын тикшерә;

Грант алучыга карата Россия Федерациясе законнарында һәм әлеге Шартнамәдә каралган, хокук бозуларны бетерүгә һәм «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү» ведомство максатчан программасы таләпләренең үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән гамәлләрне башкара.

2.2. Грант алучыга, әлеге Шартнамә төзелгән мизгелдән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, финанслау лимитлары булса, акчалар күчерү юлы белән грант суммасын түләүне гамәлгә ашыра.

2.3.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт чаралары турында» 2018 елның 17 гыйнварындагы 17 номерлы карарында каралган грант бирү тәртибе, максатлары һәм шартлары бозылу факты (фактлары) билгеләнгән яисә алар турында дәүләт финанс контроле органыннан мәгълүмат алынган очракта, шул исәптән әлеге Грант алучы тарафыннан Шартнамә нигезендә тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр күрсәтелгән очракта, шул хокук бозулар бетерелгәнче грант бирү Грант бирүче тарафыннан туктатып торыла, бу хакта туктатып тору турында карар кабул ителү датасыннан 10 эш көненнән дә соңга калмыйча катгый рәвештә Грант алучыга хәбәр ителә.

## 3. Грант алучының хокуклары һәм бурычлары

3.1. Грант алучы:

3.1.1.Федераль казначылыкның территориаль органында бюджет процессында катнашмаучы операцияләрен исәпкә алу өчен счет ача;

3.1.2.Федераль казначылыкның территориаль органына финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан субсидияләр булган чыгымнарны санкцияләүне гамәлгә ашыру өчен Россия Финанс министрлыгының «Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан акчалар булган чыгымнарны «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына федераль бюджет турында» Федераль законда каралган очракларда казначылык күзәтүендә санкцияләүне Федераль казначылыкның территориаль органнары тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 8 декабрендәге 220н номерлы боерыгы белән расланган Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан акчалар булган чыгымнарны санкцияләүне Федераль казначылыкның территориаль органнары тарафыннан гамәлгә ашыру тәртибендә каралган документларны тапшыра;

3.1.3. Шартнамәләрдә (контрактларда, килешүләрдә), түләү һәм исәп-хисап документларында, шулай ук нигези документларда «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына федераль бюджет турында» Федераль законда каралган очракларда Казначылык күзәтүендә Россия Федерациясе валютасында капитал салулар турында дәүләт контрактының, учреждение контрактының, килешүнең, шартнамәнең идентификаторын булдыру тәртибен раслау турында" Россия Казначылыгының 2018 елның 9 гыйнварындагы 5н номерлы Боерыгында билгеләнгән идентификаторны күрсәтә (____________________);

3.1.4. Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:

чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алынган әйберләрнең һәркайсының хакыннан кимендә 40 процентын үз акчалары исәбеннән һәм (яисә) кредит акчаларыннан түләнүен раслый торган документларның Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча җыелма реестрын, күрсәтелгән документларның күчермәләрен (түләү йөкләнешләренең (поручениеләрнең), шартнамәләрнең, накладнойларның, фактура счетларының, сатып алынган әйберләрне дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның күчермәләрен, сатып алынган әйберләрнең

фотографияләрен) өстәп;

максатчан чыгымнарны түләүгә түләү йөкләнешләрен (поручениеләрен), максатчан чыгымнарны түләү буенча Гранталучыда түләү йөкләмәләрен китереп чыгарган шартнамәләрне, үтәүченең (подрядчикның, поставщикның) тулы исеме, товарның (хезмәт күрсәтүләрнең) исеме, чыгымнар планы нигезендә грант чикләрендәге суммага аларның саны (күләме) күрсәтелә;

3.1.5. Грант исәбенә гамәлгә ашырыла торган операцияләрнең аерымланган аналитик исәбен алып бару йөкләмәсен үз өстенә ала;

3.1.6. Нәтиҗәлелек күрсәткечләре һәм (яисә) 1.1., 1.2., 3.1. пунктларда билгеләнгән башка күрсәткечләр зурлыгына ирешүне тәэмин итә;

3.1.7. Грант алучы грантны үзләштерә башлаган көннән алып 5 ел буена Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) «Эшчәнлек турында белешмәләр» формасы буенча нәтиҗәлелек күрсәткечләре зурлыгына ирешү турында яртыеллык һәм еллык хисаплар тапшыра. Хисаплар Грант алучы тарафыннан Идарәләргә Министрлык боерыгы белән расланган формалар буенча хисап чоры узганнан соң 10 көн эчендә тапшырыла. Идарәләр хисаплар кергәннән соң 10 көн эчендә аларны килештерәләр һәм Министрлыкка җибәрәләр;

3.1.8 Грант алган көннән соң 24 ай эчендә Министрлыкка гранттан максатчан файдалану турында, Идарә башлыгы белән килештереп, «Җыелма реестр» формасы буенча хисап тапшыра, аңа хисап документлары өстәлеп бирелә. Хисап документлары дип, законнар нигезендә шулай дип танылган документлар атала (түләүне, товарлар алуны һәм (яисә) хезмәтләр күрсәтүнераслый торган документлар, фотографияләр). Хисаплар Грант алучының имзасы һәм мөһере (булса) белән таныкланган һәм Татарстан Республикасы ______________________ муниципаль районындагы Идарә башлыгы белән килештерелгән булырга тиеш;

3.1.9. Грант акчаларын үзенең шәхси счетына акчалар кергән көннән 24 ай эчендә үзләштерә һәм грантны бары тик авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының матди-техник базасын үстерү өчен генә куллана;

3.1.10. Чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алынган мөлкәтнең, башкарылган эшләрнең, күрсәтелгән хезмәтләрнең бәясеннән кимендә 40 процентын, шул исәптән сатып алынган мөлкәтнең, башкарылган эшләрнең, күрсәтелгән хезмәтләрнең бәясеннән кимендә 10 процентын үз акчалары исәбеннән түли;

3.1.11. Грант акчаларын кулланып алынган мөлкәтне авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативының бүленми торган фондына кертә;

3.1.12. Грант акчаларын кулланып алынган мөлкәт әлеге шартнамәнең гамәлдә булу срогы (5 ел) чыкканчы читләштерелгән очракта, бюджет акчаларын кире кайтара;

3.1.13. Грант алган елда грант ярдәменең һәр 3 миллион сумына кимендә бер даими яңа эш урыны булдыра;

3.1.14. Авыл хуҗалыгы продукциясе күләменең үсешен грант бирелгән ел

алдыннан булган дәрәҗәдән кимендә 10 процентка артуын тәэмин итә;

3.1.15.Кооперативның үзе җитештергән продукциясен җыю һәм эшкәртү, транспортлау, саклау күләмнәре өлешен, бу кооперативның үзе җитештергән авыл хуҗалыгы чималыннан шул ук кооператив тарафыннан җитештерелгән беренчел эшкәртелештәге продукцияне дә кертеп, шулай ук әлеге кооператив әгъзалары өчен башкарылган эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) өлешен гомуми күләмдә 50 процентка кадәр җиткерүне тәэмин итә;

3.1.16. Грант үзләштерелгән датадан кимендә 5 ел дәвамында финанс-хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

3.1.17. Министрлык һәм дәүләт органнары тарафыннан кооперативның грант бирү һәм куллану шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр уздыруга ризалык бирә.

3.2. Икеяклы килешү буенча яклар, проект хакының чыгымнар планында күрсәтелгән кимендә 40 процентын үз акчаларыннан һәм (яисә) кредит акчаларыннан Грант алучы Федераль казначылыкның территориаль органында ачылган бюджет процессында катнашмаучы операцияләрен исәпкә алу өчен шәхси счетка күчерә, дип килешәләр.

3.3. Грант исәбенә алынган активлар Грант алучы исеменә теркәлергә һәм Татарстан Республикасы ______________________ муниципаль районы территориясендә кулланылырга тиеш.

3.4. Грант исәбенә Грант алучы тарафыннан сатып алынган мөлкәт кооперативның бүленми торган фондына кертелә һәм грант үзләштерелгән көннән 5 ел дәвамында Россия Федерациясе законнары нигезендә бүләк ителми, арендага, куллануга тапшырылмый, алмаштырылмый, пай, кертем рәвешендә кертелми яисә башка рәвештә читләштерелми.

3.5. Кооператив авыл хуҗалыгы кооперативларының ревизия берлеге әгъзасы була һәм ел саен үз эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча Министрлыкка ревизия бәяләмәсен тапшыра.

3.6. Грант алучы тарафыннан алынган акчалар исәбенә түбәндәгеләрне башкару тыела:

3.6.1. Югары технологияле чит ил җайланмаларын, чимал һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (кайтарганда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук бу чараларны алу максатларына ирешүгә бәйле башка операцияләрдән тыш, чит ил валютасын алу;

3.6.2. Башка юридик затның (юридик затның ияртчен җәмгыятенең) устав (җыелма) капиталына взнос буларак, башка юридик затның (юридик затның ияртчен җәмгыятенең) мөлкәтенә аның устав (җыелма) капиталын арттырмаслык кертем буларак, әгәр максатчан акчалар бирү тәртибен җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны күрсәтелгән юридик затка (юридик затның ияртчен җәмгыятенә) аның Россия Федерациясе үзәк банкы учреждениесендә яисә кредит оешмасында ачылган счетларына күчерү мөмкинлеге каралмаган булса;

3.6.3. Акчаларны депозитларга, шулай ук башка финанс

инструментларына урнаштыру масатларында, әгәр федераль законнарда яисә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында башкасы билгеләнмәгән булса;

3.6.4. Грант алучыга банкта ачылган счетларга акчалар күчерү тыела, моңа түбәндәге очраклар керми:

3.6.4.1. Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә юридик затның йөкләмәләрен түләү;

3.6.4.2. Хезмәт хакына исәпләнгән суммаларны һәм социаль түләүләрне исәпкә алып, юридик затның хезмәт өчен түләү буенча йөкләмәләрен түләү, шулай ук Грант алучының штатында тормый торган, максатчан акчалар бирелгәндә билгеләнгән максатларга ирешү өчен җәлеп ителгән хезмәткәрләр файдасына башка түләүләр;

3.6.4.3.Финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан акчалар булган Грант алучы тарафыннан фактта башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр, әзерләнгән продукция өчен түләү, әгәр Грант алучы эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү һәм продукция әзерләү өчен башка юридик затларны җәлеп итмәсә, шулай ук нигезе документларны һәм (яисә) килешүләрдә, дәүләт контрактларында, капитал салулар турындагы шартнамәләрдә, учреждениеләр контрактларында, субсидияләр бирү турындагы шартнамәләрдә (контрактларда, килешүләрдә) яисә норматив хокукый актларда каралган башка документларны биргәндә;

3.6.4.4. Грант алучы тарафыннан тотылган 3.6.4.3. пунктында күрсәтелгән чыгымнарны раслый торган документларны, түләү йөкләнешләре, түләү йөкләнешләре реестрлары күчермәләрен, шулай ук капитал салулар турында килешүнең, дәүләт контрактының, шартнамәнең, субсидияләр бирү турында учреждение контрактының һәм шартнамәсенең (контрактның, килешүнең) яисә башка норматив хокукый актның күчермәләрен тапшырганда (әгәр капитал салулар турында дәүләт контрактында, шартнамәсендә, учреждение контрактында һәм шартнамәсендә (контрактында, килешүендә) юридик зат тоткан чыгымнарны (чыгымнар өлешен) каплау каралган булса), Грант алучы тарафыннан тотылган чыгымнарны (чыгымнар өлешен) кайтару.

3.6.5. Юридик зат – максатчан акчалар алучы – белән төзелгән шартнамәләр (контрактлар, килешүләр), элемтә хезмәтләренә, коммуналь хезмәтләргә, электр энергиясенә, авиация һәм тимер юл билетларына, шәһәр һәм шәһәр яны транспортында йөрү өчен билетларга, матбугат басмаларына язылуга, арендалауга, юридик затларга караган инженерлык челтәрләрен, коммуникацияләрне һәм корылмаларны Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнары нигезендә күчереп урнаштыруга (яңадан төзүгә, тоташтыруга) шартнамәләрдән тыш, шулай ук иминләштерү законнары нигезендә төзелгән иминият шартнамәләре нигезендә банкларда ачылган счетларга күчерү.

3.7. Грантны куллану йомгаклары буенча Грант алучы гранттан максатчан файдалану турында «Килештерү кәгазен» Министрлыкның

тармак бүлекләре, аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлеге башлыкларыннан һәм кооперативларның матди-техник базасын үстерүгә грантлар бирү өчен авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларын сайлап алу буенча конкурс комиссиясе рәисеннән имзалата.

## 4. Якларның җаваплылыгы

4.1. Яклар үз йөкләмәләре өчен законнар нигезендә җаваплы булалар. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары грант бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен һәм аннан максатчан файдалануны законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерәләр.

4.2. Бирелгән грантлар, әгәр аларны бирү тәртибе, Шартнамәнең 3.1. пунктында билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, грантлардан максатчан файдаланмау йә грант алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирелү фактлары ачыкланса, Министрлыкның таләбе алынган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

4.3. Грант алучы тарафыннан Министрлыкка һәм Идарәгә тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык Грант алучыга йөкләнә.

4.4. Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемнә ихтыярый рәвештә кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә тартып алынырга тиеш.

4.5. Шартнамәне гамәлгә ашыру барышында барлыкка килергә мөмкин булган каршылыклар Яклар сөйләшүләре аша хәл ителергә тиеш. Каршылыкларны сөйләшүләр аша хәл итеп булмаган очракта, алар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителергә тиеш.

4.6. Яклар Шартнамә буенча йөкләмәләрне тулысынча яисә өлешчә үтәү өчен җаваплылыктан бары тик форс-мажор хәлләр (РФ ГК, ст. 401, п.3) барлыкка килгәндә генә азат ителәләр. Әмма мондый хәлләр барлыкка килү үзе Грант алучының үз йөкләмәсен үтәвен туктатмый, әгәр аны бу хәлләр беткәннән соң үтәп була торган булса.

4.7. Шартнамәне вакытыннан алда өзү, Якларның үзара килешүе буенча бюджет законнары нигезендә тиешле бюджетка___________сум (______________________сум) күләмендә грантны керткәч, башкарыла.

(сүзләр белән язылa)

4.8. Шарнамәне Грант бирүче тарафыннан суд тәртибендә, Россия Федерациясе Граждан кодексының 450 статьясы нигезендә өзү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

4.8.1. Грант алучы тарафыннан грант үтәлеше турында хисаплар бирелмәсә яисә алар тулысынча бирелмәсә һәм Шартнамә йөкләмәләре үтәлмәсә;

4.8.2. Хисап документлары тикшерелгәндә Грант бирүче тарафыннан

ачыкланган белешмәләрне Грант алучы белә торып бозса;

4.8.3. Грант акчаларының максатчан тотылмавы ачыкланса;

4.8.4. Грант алучы тарафыннан эшчәнлек грант алынган көннән биш ел эчендә туктатылса һәм (яисә) проектны гамәлгә ашыру буенча үзенә алынган йөкләмәләр Грант алучы тарафыннан үтәлмәсә;

4.8.5. Әгәр проект Шартнамә төзелгән көннән 24 ай эчендә мөһим сәбәпләрсез (каршы тора алмаслык хәлләр, ягъни гадәттән тыш хәлләр (җир тетрәү, давыл, су басу, янгын һ.б.лар) гамәлгә ашырылмаса.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Шартнамә аны имзалаган көннән үз көченә керә һәм 20______елның ___ __________ кадәр гамәлдә була.

5.2. Шартнамәгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара килешүе буенча аңа Яклар тарафыннан имзалана торган өстәмә язма килешү төзү юлы белән кертелә.

5.3. Шартнамә тигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә төзелде, Якларның һәркайсына берәр нөсхә бирелде.

## 6. Якларның реквизитлары һәм имзалары

Грант бирүче: Грант алучы:

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | ______________________<br>теркәлү адресы:<br>______________________<br>______________________ |
| 420014, Россия, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Федосеев ур., 36 йорт | яшәү адресы: ____________<br>______________________ |
| р/с 40201810900000000002 НБ БҮЛЕКЧӘСЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БИК 049205001<br>Татарстан Республикасы буенча УФК (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | паспорт: серия ______, №____________<br>бирелү<br>урыны:______________________<br>бирелү дата: ________________<br>р/с ______________________<br>______________________<br>(банк исеме)<br>к/с ______________________<br>______________________<br>(банк исеме) |

| | |
|---|---|
| Аппаратының ш/сч. ЛБ 007090001<br>ИНН 1654019555<br>КПП 165501001<br>ОГРН 1021602854580 | БИК ______________________<br>банкның ИНН<br>______________________ |
| | КПП ______________________ |
| Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры | Кооперативның ОГРН ______________<br>Кооперативның ИНН ____________ |
| М.Г. Әхмәтов ________________<br>(имза) | ________________ ________________<br>(Фамилиясе, исеме, ат.ис.) (имза) |
| Мөһер урыны ________ 20__ ел. | Мөһер урыны (булса) __________ 20__ ел |